РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

28 май, 2026 ел Кукмара ш. № 51

«Татарстан Республикасы Кукмара районының Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Кукмара муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара районының Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән җирлекләр халкының ризалыгын, шулай ук Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерүне исәпкә алып, Кукмара муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара районының Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы проектын караганда, Татарстан Республикасы Кукмара

муниципаль районы Башлыгы урынбасары Гаянова Резеда Нурислам кызын Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы вәкиле итеп билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның 12 декабрендәге 27 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев